**"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге «муниципаль берәмлегенең ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«21» ноябрь 2019 ел № 3

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге составына керүче Югары Яке авылында Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы нигезендә», «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы», "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст.», Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлегендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану һәм "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлегенең Югары Яке торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Югары Яке авылы-Үзәк урамындагы юлларны грунт вак таш җәеп ремонтлау. (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Кече Кирмән авыл җирлегенең Югары Яке авылында җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту.

« ӘЙЕ» «ЮК»

соравы буенча 2019 нчы елның 21 нчы ноябрендә үткәрелгән гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 132 граждан кертелгән;
гражданнар җыенында катнашучы 73 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Халык җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе " позициясе өчен»- барлыгы 73 кеше тавыш бирде;
“Юк” дип тавыш бирүче булмады.
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Югары Яке авылында үткән гражданнар жыенын- уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлегенең Югары Яке авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлегенең Югары Яке торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Югары Яке авылы-Үзәк урамындагы юлларны грунт вак таш җәеп ремонтлау. (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Кече Кирмән авыл җирлегенең Югары Яке авылында җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту.

« ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль Югары Яке хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Кече Кирмән авыл җирлеге
Советы рәисе Х.Х.Мубаракшин